КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 ноябрь г.Казань № 930

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

01.06.11.01,01.06.11.04, 01.06.11.05,01.06.11.06, 01.06.11.10 кодлы функцияләрне төшереп калдырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 ноябрь, 646 нчы; 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче;

2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче һәм 3.2 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү (01.06), шул исәптән:

атмосфера һавасын саклау өлкәсендә (01.06.06<*>);

радиация куркынычсызлыгын билгеләнгән тәртиптә тәэмин итү (01.06.08<*>);

Татарстан Республикасында радиация торышын билгеләнгән тәртиптә тикшерүдә тоту (01.06.11.09<*>);

җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу (01.06.01<*>), шул исәптән:

Россия Федерациясе белән берлектә, Татарстан Республикасы территориясендә җир асты байлыкларының бердәм дәүләт фонды белән эш итүдә катнашу (01.06.01.1<*>),

минераль-чимал базасын өйрәнү, файдалану һәм торгызу белән идарә итү (01.06.01.2<*>),

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.06.01.3<*>),

файдалы казылмалар запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик, икътисадый һәм экологик мәгълүматка дәүләт экспертизасын билгеләнгән тәртиптә үткәрүне оештыру (01.06.11.08<*>);

Татарстан Республикасы территориясендә геология-разведка һәм геодезия эшчәнлеге белән идарә итү (03.01.10<*>);

хуҗалык эшчәнлеген һәм башка эшчәнлекне (федераль дәүләт экология күзәтчелегендә тотылырга тиешле объектлардан файдаланып эшләнә торган эшчәнлектән башка) гамәлгә ашырганда түбәндәге юнәлешләр буенча төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә тоту (01.06.11):

су объектларыннан (федераль дәүләт күзәтчелегендә тотылырга тиешле су объектларыннан башка) файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә, шулай ук файдалануы һәм саклануы төбәк дәүләт күзәтчелегендә тотылырга тиешле су объектларында урнашкан гидроэнергетика объектларының саклык зоналары чикләрендәге яр буе полосасы кишәрлекләреннән (шул исәптән гидроэнергетика

объектларына тоташкан кишәрлекләрдән) файдалануның һәм судан файдалануның аерым шартлары үтәлешен төбәк дәүләт күзәтчелегендә тоту;

төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә тотылырга тиешле хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек объектларында атмосфера һавасын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегендә тоту;

төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә тотылырга тиешле хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегендә тоту;

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата җир асты байлыкларын геологик өйрәнүне, нәтиҗәле файдалануны һәм саклауны төбәк дәүләт күзәтчелегендә тоту;

үзәкләштерелгән субүлгеч системасы аша агып төшә торган суларны агызуны төбәк дәүләт күзәтчелегендә тоту.

3.2. Министрлык үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

социаль-икътисадый программалар эшләү (01.01<*>);

инвестиция эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу (01.10<*>);

инновация эшчәнлеген үстерү белән идарә итү (01.11<*>);

Татарстан Республикасының ведомстволар дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2<*>);

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән – сәнәгать белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.01<*>);

Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән бюджет процессы (Татарстан Республикасы һәм бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары) белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02.1<*>);

Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән тыш) функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.02<*>);

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01<*>);

Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы территориясен планлаштыру схемасын әзерләүне тәэмин итү (01.05.01.01<*>);

территорияне планировкалау документларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.02<*>);

шәһәр төзелешен проектлауның төбәк нормативларын әзерләүне тәэмин итү (01.05.03<*>);

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез мөлкәттән (биналардан, корылмалардан), транспорттан, җиһазлардан, мәдәни мирас объектларыннан файдалану белән идарә итү (01.07.01<*>);

Татарстан Республикасының җир ресурслары белән идарә итү (01.07.04<*>);

Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

хезмәт өчен түләүне, хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм хезмәт мөнәсәбәтләренә турыдан-туры бәйле мөнәсәбәтләрне җайга салу (01.13.01<*>);

хезмәтне саклау белән идарә итү (01.13.02<*>);

Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы белән – түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар эшләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01<*>);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03<*>);

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1<*>).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\930.docx